| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | с.Старое Дрожжаное | **КАРАР** |

2023 елның 5 мае № 28/5

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2016 елның 14 сентябрендәге 11/3 номерлы (2020 елның 12 декабрендәге 3/4 номерлы редакциядә) карары белән расланган муниципаль мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына арендага бирү тәртибенә түбәндәге эчтәлекле **3.1 пунктын өстәп**, үзгәреш кертергә:

«Муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган күчемсез мөлкәткә түләү бер тапкыр яки айлык яки квартал саен тигез өлешләрдә түләүләр аша рассрочка белән башкарыла. Мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда түләүне кичектерү срогы күчемсез мөлкәт өчен биш ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.».

2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров